УДК 821.512.145

*Т.Ш. Гыйлаҗев*

# Ф. ӘМИРХАННЫҢ ӘДӘБИ-ТӘНКЫЙДИ ЭШЧӘНЛЕГЕ

В данной работе рассматривается литературно-критическая деятельность Ф. Амирхана. Оценивается вклад писателя в формирвание татарской литературной критики. В статье выявляются основные темы и характеристики данного вида его творчества.

**Ключевые слова:** критика, писательская критика, типы критики, реалистическая критика, народность, жанры, методы, репутация.

Әдәби җәмәгатьчелек арасында тирән белеме һәм фикер үткенлеге белән танылган абруйлы Ф. Әмирхан татар әдәби тәнкыйтенә нигез салучыларның берсе булып тора. Ул киң карашлы, нечкә зәвыкле, эрудицияле тәнкыйтьчеләрдән санала. Аның бу төр эшчәнлегендә агымдагы тәнкыйди барышны бәяләү төп юнәлешне тәшкил итсә дә, тәнкыйтьнең предметы, жанрлар системасы, әсәрне бәяләү принциплары, алым-методлары, типлары һәм юнәлеш-агымнары кебек нәзари мәсьәләләр дә гыйльми күзаллана. Г. Сәгъди аның үткен каләмен, таләпчән, принципиаль тәнкыйтен күздә тотып, «карчыга күзле» беренче әдәби тәнкыйтьче» [Сәгъди, б. 15] дип атый.

Яңа татар әдәбиятының үсеш юнәлешен билгеләгән реалист Г. Исхакый, Г. Тукай, Г. Камал, Г. Коләхмәтов, М. Гафури иҗатлары Ф. Әмирхан тәнкыйтенең бәяләү объекты булып тора. Аларның әдәби әсәрләре басылып чыгу уңаеннан дөнья күргән мәкаләләрендә, рецензияләрендә әдәбиятның иҗтимагый роле, чынбарлыкка мөнәсәбәте, сүз сәнгатенең милли характеры, реализм, халыкчанлык һәм әдәби осталык, театр тәнкыйте мәсьәләләре күтәрелә. Әдәбият һәм сәнгатьнең бурычын ул мәгърифәт тарату һәм әхлак төзәтүдә билгеләү белән бергә, иҗтимагый-милли мәсьәләләрне күтәрүдә, сәяси һәм икътисади стройның асылын сәнгатьчә ачып бирүдә билгели, ягъни «әдәбиятның иҗтимагый ягын югары күтәрә, аның җәмгыятькә тәэсир көчен фәнни мәктәп, юнәлешенең нигезен сала, җәмгыяви һәм милли мәсьәләләрне хәл иткәндә төп сүзне әйтүче икәнлеген күз уңында тота» [Заһидуллина, б. 173].

Ф. Әмирхан башлангыч чор тәнкыйди эшчәнлегендә, шушы ноктадан якын килеп, заман таләпләренә җавап бирмәгән Г. Тукайның тәүге шигырьләрен, Я. Вәли, М. Гафури, М. Фәүзи әсәрләрен тәнкыйтьли. Мәсәлән, Г. Тукайның «Мужик йокысы» исемле А.В. Кольцовтан (1809–1842) ирекле тәрҗемәсендә авыл мужигы үзенең ялкаулыгы аркасында ярлы, авыр тормышта яши дигән идея үткәрелә. Ә Ф. Әмирхан «Мал юк дип зарланма, үзеңнән күр аны» дигән шигырьләрнең мәгънәләре берлә

Русия җир тарихын вә сәясәтен белгән кешеләр канәгать итмәячәктер» [Әмирхан, 1986, б. 22], – дип искәртә. Я. Вәлинең пьесасына язылган «Ачлык кушты» (1908) рецензиясендә тәнкыйтьче иҗтимагый-социаль проблемаларны Россиянең социаль-икътисади җирлеге белән тыгыз бәйләнештә сурәтләүне таләп итеп чыга: «Мондый олуг темалар *(ачлык темасы. – Т.Г.),* хосусән, бөтен бер халыкның, хәтта бер мәмләкәтнең халәте икътисадиясеннән *(икътисади хәленнән. – Т.Г.)* килгән күренешләр хакында язылган драмалар социальный характерда язылырга вә асыл сәбәп булган яманлык, төрле тарафларыннан вә сәбәпләре белән тәфтиш ителеп *(аңлатылып. – Т.Г.),* укучы күз алдына тәрсим ителергә *(сурәтләнергә. – Т.Г.)* тиештер. Әмма «Ачлык кушты» драмасы нәкъ шушы нәрсәләрдән мәхрүм» [Әмирхан, 1986, б. 85]. Г. Коләхмәтовның «Яшь гомер»ендәге Зөләйха образы гәүдәләнешендәге җитешсезлек тә капитал, акча-товар мөнәсәбәтләре яссылыгында күрсәтелә: «Мөхәррир монда капиталның тугрыдан-тугры көчләве буенча кияүгә чыгуны тасвир иткән булса, драманың гомуми фикеренә кәмаль *(камиллек. – Т.Г. )* вә яңа рәүнәкъ *(төс. – Т.Г.)* биргән булыр иде» [Әмирхан, 1986, б.41].

Әдәби иҗатка йогынты ясаган шартлар, иҗтимагый күренешләр, милли чынбарлык вакыйга-хәлләре белән әсәр арасындагы бәйләнешләр беренче планга чыгарылу, әдәби әсәрне җәмгыятькә, андагы процессларга бәйле тикшерүгә йөз тоту Ф. Әмирхан тәнкыйтен публицистик тип кысаларында тикшерергә мөмкинлек бирә. «Әдәби әсәргә нисбәтле язылган текстта иҗат мәсьәләсе, аңа эстетик яктан бәя бирү теге яки бу дәрәҗәдә урын алса да, язма авторы яшәешнең күп төрле сорауларын читләтеп үтә алмый, ягъни чор-заман проблемалары фәлсәфи, әхлакый, сәяси, тарихи мәсьәләләр белән үрелеп, ялганып китә» [Закирзянов, 2011, с. 209], – дип яза Ә. Закирҗанов. Ф. Әмирхан тәнкыйте белән XX гасыр башында үсеш юлына чыккан публицистика арасында бәйләнеш аеруча көчле.

Әдәби тәнкыйтьнең юнәлешләрен һәм агымнарын аерып чыгарып, аларның үзенчәлекләрен билгеләү омтылышы 1920 еллар татар тәнкыйтендә үк башлана. Әдәби-тәнкыйди фикерне тарихи процесс буларак тикшерү юлында беренче сукмакны салган Г. Сәгъди, Ф. Әмирханның әдәби әсәрне бәяләү принципларына таянып, аны «реалист тәнкыйтьче» [Сәгъди, б. 16] дип атый. «Реаль тәнкыйть нигезендә чор картинасын тудыру, ягъни заман, хакимият, гомумән системаның бөтенлекле образын күз алдына бастыру тора. Аның концептуаль җирлеген әсәрләрдә тудырылган тормыш моделе үзенчәлекләре билгели» [Закирзянов, с. 238].

Ф. Әмирханның Г.Исхакый әсәрләренә язылган рецензияләрендә матур әдәбиятның реаль чынбарлыкны тулы һәм дөрес чагылдыру хасияте бары тик җанлы һәм тормышчан образлар, табигый типлар тудыру, детальләр

дөреслеге ярдәмендә тормышка ашырыла дигән фикер, кагыйдә үзәккә куела. Мәсәлән, «Алдым-бирдем» рецензиясендә тәнкыйтьче пьесаның сюжеты нигезендә яткан төп каршылыкны – яңа тормыш белән иске тормыш арасындагы көрәшне билгели, милли чынбарлыктагы тартышны типлар аркылы анализлый. Тип терминын түбәндәгечә аңлата: «Тип» дип, мәгыйшәттән *(тормыштан. – Т.Г.)* алып ясалган вә тасвир ителә торган мәгыйшәтнең халыклары арасында махсус бер фиркагә *(катлауга. – Т.Г.)* тугры килә торган сурәте әдәбиягә әйтеләдер» [Әмирхан, 1989, б. 71]. «Алдым-бирдем»дәге һәрбер персонажның татар тормышыннан алынып, тип дәрәҗәсенә җиткерелеп эшләнүе билгеләнә.

«Солдат» (1908), «Мөгаллим» (1914), «Зөләйха» (1917) рецензияләрендә дә Ф. Әмирхан реалистик тәнкыйть кануннары белән эш итә. «Гаяз» (1907) мәкаләсендә, иң беренче нәүбәттә, Г. Исхакый каләменең реалистик табигатен тотып ала: «... язган нәрсәләре белән йөрәкләрне кузгата, күңелгә әллә нинди фикер вә хисләр бирә вә мәгыйшәтнең начар вә яхшы якларын ачык күрсәтә торган мөхәррир» [Әмирхан, 1989, б. 28]. Ул әдип әсәрләрендә гәүдәләнгән тормыш материалының иҗтимагый-социаль, милли азатлык мәсьәләләре белән тыгыз бәйләнешенә һәрдаим үз игътибарын юнәлтеп бара.

«Солдат» рецензиясендә, автор җәмгыятьтә хөкем сөргән сәяси хәлгә бәйле рәвештә, повестька тиешле, теләгән бәя бирә алмавын сиздертә. Г. Исхакыйның иҗтимагый-сәяси эшчәнлеген, шуның бер өлеше «Зиндан»да тасвир ителүен хуплый. Әсәрне әдәбият һәм фикер үсешен күрсәтә торган повесть дип атый. «Мөгаллим» рецензиясе пьесаның «Шәрык» клубында уйналу мөнәсәбәте белән язылу сәбәпле, театр тәнкыйте белән үрелеп китә. Кимчелек буларак күрсәтелгән бертарафлылык, безнең карашыбызча, әсәрдә сыйнфый көрәш, азатлык хәрәкәтләре яктыртылуга тиешле игътибар бирелмәүне белдерә. Алдагы рецензияләрендәгечә пьесаны бәяләүдә төп бизмән булып татар тормышын реаль вакыйгаларда дөрес итеп үз кыяфәтендә чагылдыру принцибы тора: «Татар мөгаллиме тормышының Гаязның маһир куллары тарафыннан ясалган картинасы безнең алда авыр, фаҗигале вә өмидсез булып басып торадыр. Моны күреп җан ачына, сызлана, пьеса бер трагедиягә, рухани трагедиягә әйләнә» [Әмирхан, 1989, б. 247].

Билгеле булганча, «Зөләйха» фаҗигасе 1912 елда язылып бетсә дә, 1917 елга кадәр рәсми төстә тыелып килә. 1917 елгы февраль инкыйлабы биргән мөмкинлекләрдән файдаланып, «Зөләйха» пьесасы «Сәйяр» труппасы тарафыннан аның җитәкчесе һәм режиссеры Г. Кариев бенефисына 1917 елның 17 мартында Казанның Зур драма театры сәхнәсендә күрсәтелә. Бу зур тарихи фаҗига милли театр хәрәкәтендә әле күрелмәгән яңа сәхифә ача. Җәмәгатьчелек бик җылы кабул иткән бу спектакль вакытлы матбугатның да игътибарын бик тиз

арада үзенә җәлеп итә. Газетада басылган беренче язманың авторы Ф. Әмирхан әсәрнең темасының иҗтимагый-милли әһәмиятенә басым ясый: «Зөләйха – талантлы каләм, хәссас (сизгер) рух белән язылган, урыны-урыны белән гаять тирән рухани фаҗигане караучының алдына китерә торган пьесадыр. Бу иске хөкүмәткә каршы гаять куәтле бер обвинительный акт булуы белән бергә, милләтемезнең үз кодсияте *(изге. – Т.Г.)* юлында һичбер төрле фидаилектән кире тормас дәрәҗәдә рухка малик фәрдләре *(ия шәхесләре. – Т.Г.)* барлыгын күрсәтә вә бөтенлегебезне саклауда исламның нинди шәрәфле бер роль уйнаганлыгын исбат итә торган бер васикадыр *(нигезле дәлилдер. – Т.Г.)*» [Әмирхан, 1989, б. 327–328]. Рецензия эчтәлеге, Ф. Әмирханның киң диапазонлы публицистикасы белән кушылып китеп, татар халкын милләт буларак саклап калуда ислам диненең ролен күрсәтә. Аерым фактлар, сыйфатлар белән конкретлаштырылмаса да, «Зөләйха» фаҗигасе сәнгатьчә эшләнеше, камиллеге ягыннан татар драма әсәрләреннән аерып куела: «халис *(саф. – Т.Г.)* әдәби җәһәтеннән дә, пьеса мәүҗүд *(бар булган. – Т.Г.)* пьесаларыбызның 99 фаизеннән өстен тора вә урыны-урыны белән гүзәллекнең югары дәрәҗәләренә ирешәдер» [Әмирхан, 1989, б. 329].

Ф. Әмирхан тарафыннан әдәби тәнкыйтьнең теоретик мәсьәләләре эшләнүгә аның Рус – Аурупа әдәбият белеме, мәдәнияте ирешкән казанышлар белән танышлыгы зур йогынты ясый [Gilazov, Karabulatova..., 2015, p. 510]. Аңа типик характерлар тудыруда И.С. Тургенев тәҗрибәсе ярдәмгә килсә, психологик анализга ирешү осталыгы Л.Н. Толстой ярдәменнән башка була алмаган. Н.В. Гогольнең тууына 100 ел тулу уңаеннан язылган юбилей мәкаләсендә әдипнең рус әдәбияты мәйданында тоткан урыны хакындагы уйланулары Ф. Әмирханны татар әдәбиятының үсеш юнәлеше мәсьәләсенә тоташтыра. Ул татар халкының көнитешен, яшәешен уңай якка үзгәртү, милли әдәбиятны яңарту өчен рус әдәбиятына йөз тотарга тиешлекне дәлилли: «Ватандашларыбыз русларның мәгыйшәти руханилары (*дөньяви караш иҗат итүчеләре. – Т.Г.)* белән белешләнү безгә файдалы гына түгел, бәлки важибтыр *(тиештер. – Т.Г.):* без алар аркылы Гарби Европа белән белешләнәчәк һәм тормышыбызда һәр көнне рус мәгыйшәте белән очрашып торабыз һәм торачак; билахирдә *(ахырда. – Т.Г. ),* рус әдәбияты безнең яңа әдәбиятыбызга күп тәэсир итә генә түгел, бәлки күп ярдәм итәдер» [Әмирхан, 1986, б. 94].

Ф. Әмирханның әдәби-тәнкыйди эшчәнлегендә Г. Тукайның шигъри осталыгын, халыкчанлыгын һәм миллилеген, тел-үзенчәлекләрен ачып бирү, шәхесенең иҗтимагый кыйммәте кебек мәсьәләләр зур урын алып тора. Шагыйрь иҗатын чагыштырма-тарихи ысул белән әдәби-мәдәни бәйләнешләр контекстында тикшерү юнәлешенең юл башында да Ф. Әмирхан тора. Тәнкыйтьче шагыйрьнең

басылып чыккан һәрбер шигырь җыентыгына язылган бәяләмәләрендәге караш-хөкемнәре, аның шигъри дөньясын бәяләү принциплары һәм кагыйдәләре белән Тукай гыйльмиятенең фәнни концепциясен эшләүгә зур өлеш кертә. Г. Тукайның шигырьләренең телен этрафлы итеп анализлый, үзгәрешен күзәтә һәм шуның белән тел-өслүбне әсәр бәяләүнең мөһим үлчәменә әйләндерә. «Аның «Ислах»тагы каләм иптәше булган Г. Тукайның шигырьләрен яңа эзгә төшерүдә, бигрәк шагыйрьнең телдә татарлашуына бу тәнкыйтьләрнең (һәм, гомумән, араларындагы якын мөнәсәбәтнең. – *Җ.В.*) тәэсире булганлык һич шөбһәсез» [Кара: Гыйлаҗев, б. 182], – дип яза Җ. Вәлиди.

Ф. Әмирханның әдәбиятта халыкчанлык һәм миллилек турындагы әдәби-эстетик карашлары төгәлләнгән бер системаны барлыкка китерә: «Үз милләтеңне кирәгенчә сөяр өчен, аның рухын аңларга, аның халәте руханиясендәге бик нечкә мусика *(музыка. – Т.Г.)* тамырларын чиертеп, шуларның чыгарган тавышларын тыңлый белергә кирәктер. Шул вакытта гына кабык астына яшерелгән куәи руханияне *(эчке көчен. – Т.Г.),* ләтафәт *(гүзәллек. – Т.Г.),* матурлыкны күреп яратырга мөмкин буладыр. Бер кавемнең рухын аңлау фәкать аның әдәбияты аркылы гына мөмкиндер [Әмирхан, 1986, б. 106]. Монда ул, һичшиксез, милләтнең язмышы, аны борчыган проблемалар, уй-фикерләрен аларның кайгы-шатлыкларын күздә тота, милләтнең ерак данлы һәм шанлы тарихын, үсешен белергә чакыра.

Тәнкыйтьче Г. Тукай шигъри дөньясының халыкчанлыгын аңлауга да шушы ноктадан якын килә: «Тукаев кайгы-хәсрәт баласы, моңнар шагыйре, авыр тойгылар, авыр мәшәкатьләр җырчысы иде... Милләтебезнең бөтен халык җырларындагы төп аһәң, кайгы, хәсрәт, авыр моң аһәңе аның шигырьләрендә дә төп көй, әсас *(нигез. – Т.Г.)* иде. Менә шуңар күрә аны халык бик яшьләй үз шагыйре итеп таныды; аны аңлады, ул җырлаган нәрсәләрнең үз рухындагы нәрсәләр икәнен тойды» [Әмирхан, 1986, б. 115].

Аерым бер мәсьәләләрдә Г. Ибраһимов, шулай ук Г. Исхакый карашлары белән дә уртаклык-якынлык сизелгән «Күпме какканны вә сукканны күтәрде бу ятим» (1923) мәкаләсендә Ф. Әмирхан шагыйрь иҗатына бәя биргәндә, культура-тарих мәктәбе кагыйдәләренә таяна. Иске мәдрәсә биргәннән артмаган гыйлем, иске төрек-татар әдәбияты җыйганнан бер генә карыш та уза алмаган «әдәбият танышлыгы»; «төньякның ярлы, мескен табигате белән чикләнеп калган табигать тәэсираты», Казан белән Җаек арасында чикләнгән тормыш; фикере, гыйлеме, зәвыгы яхшы тәэсир итәрлек даирәгә кермәү, Ф. Әмирхан карашынча, Тукайның тумыштан килгән талантына киңәергә, үсәргә мөмкинлек бирми, ул тумыштан бирелгән сәләт, «талант бөресен ачмыйча, ача алмыйча һәлак булды» [Әмирхан, 1986, б. 176].

Ф. Әмирханның бу төр иҗатында Г. Тукай шигърияткен

пропагандалау, рухи мирасын һәм шәхесен субъектив бәядән, нахак сүзләрдән саклау, әдәби абруе проблемасы кызыл җеп булып сузыла [Гилазов, с 181]. Шундый хезмәтләрнең берсе – «Татар шагыйрьләре» 1908 елда язылып, «Дамелла» имзасы белән «Әл-ислах» газетасында басылып чыга. «Волжско-Камская речь» газетасында цензор, педагог, мәктәпләр инспекторы һәм Татар укытучылар мәктәбе укытучысы Альберт Петрович Пинкевич (Пенькевич) (1884–1939) «Очерки новейшей татарской литературы» дигән мәкаләсен бастыра. «Камско-Волжская речь» – 1908–1918 елларда Казанда рус телендә нәшер ителгән көндәлек иҗтимагый-сәяси, әдәби һәм икътисади газета. А.П. Пинкевич XX гасыр башы татар әдәбиятына күзәтү ясап, Г. Тукай һәм М. Гафури иҗатлары нигезендә татар шигъриятендә күзәтелгән тенденцияләрне барлый. А. Пинкевич үзенең мәкаләсендә «У Тукаева много истинной поэзии, но морализм, проповедь сводит на нет его произведений. Он касается всех сторон татарского быта и диктует правила жизни. <…> Это *(М. Гафури. – Т.Г.)* яркий националист, в глубоком значении этого слова и поэтому большой популярности не имеет» [Пинкевич, 1908] дип, Г. Тукай шигырьләрен сәнгатьчә эшләнеше ягыннан югары бәяли, анда язучылык таланты барлыгын таный; ә М. Гафури әдәби әсәрләренең тар милли характерына үзенең тискәре мөнәсәбәтен белдерә. Шагыйрь иҗатының тәрҗемә эшчәнлеге мәкалә авторы тарафыннан югары бәяләнә: «У Тукаева много подражаний Байрону, Лермонтову, Пушкину. <…> Точных переводов нет. Даже такие стихотворения, как «Что ты спишь, мужичок» он переделывает на свой лад, применяя его к татарскому быту» [Пинкевич, 1908].

Бу мәкаләгә җавап төсендә «Волжский листок» газетасында Касыйм Уралец тәхәллүсе белән «Татарские поэты» язмасы дөнья күрә. «Волжский листок» – 1904–1909 елларда Казанда рус телендә нәшер ителгән газета. Язма авторы А. Пинкевичның фикерләрен кире кагып, киресенчә, Тукайны шигырьләр саны азлыкта, тәрҗемәләре уңышсыз булуда, тел-стиле ямьсезлектә, урам теле белән язуда гаепли: «Мы со своей стороны заметим, что эти “томики” не более, как две тощие книжонки, заключающие в себе 10–15 оригинальных стихотворений, а в остальном заполненных неудачными переводами из Лермонтова и Пушкина» [Уралец, 1908]. К. Уралец Гафуриның Россиядә һәм Себердә танылганлыгы һәм популярлыгы турында яза. Аның карашынча, М. Гафури, шөбһәсез, яңа татар әдәбиятының бизәге. Аны Америка шагыйре Уитмен Уолт (1819–1892) белән янәшә куя.

Татар әдәбиятының үсеш тенденцияләре хакында А. Пинкевич карашлары белән килешкән хәлдә, К. Уралец тарафыннан шагыйрьләр иҗатына бирелгән бәя бәхәс уята. Тел чуарлыгы, гарәп, фарсы сүзләренең еш кулланылуы шул чор шигъриятe өчен гомуми күренеш. Тукайда гына түгел, М. Гафурида

да башка телләрдән алынган гыйбарәләр белән язылган шигырьләр бар. Тукай, тәрҗемә эшен үзенчәлекле әдәби иҗат алымы дәрәҗәсенә күтәреп, рус һәм аның аша Аурупа шагыйрьләренең әсәрләрен уңышлы тәрҗемә итә һәм шул юл белән татар халкын Европа әдәбиятына һәм мәдәниятенә якынайта.

Дөрес, полемикада катнашучылар бәхәс кызулыгы аркасында урыны-урыны белән арттырып җибәрәләр, төгәлсезлекләр ычкындыралар [Нуруллин, б. 33], Ф. Әмирханга да урыны белән объективлык җитми. Г. Тукай шигърияте хата, ялгыш бәяләүчеләрне кире кагу белән мавыгып китеп, ул аерым бер мәсьәләләрдә М. Гафури шигъриятенә тенденциоз якын килә. Шагыйрь поэзиясенең иҗтимагый-милли әһәмиятен, аның байлыгын күреп бәяләп җиткерми.

Күзәтүләргә нәтиҗә ясап, түбәндәгеләрне әйтергә мөмкин. Татар әдәби тәнкыйте үткән юлны өйрәнүче галимнәр хезмәтендә Ф. Әмирхан бертавыштан бу иҗат төренә нигез салучы буларак таныла. Тәнкыйтьче үзенең күпсанлы мәкаләләре, рецензияләре белән татар әдәбиятының яңару процессын тизләтә. Ул тәнкыйди эшчәнлегендә рус әдәбият белемендә калыплашкан һәм XX гасыр башында милли әдәби-гыйльми фикер тарафыннан үзләштерелгән культура-тарих мәктәбенең кагыйдәләре, әдәби кануннарына таянып татар реалистик тәнкыйтенә нигез сала. Татар әдәби тәнкыйтенең нигез принциплары, әдәби әсәрне бәяләү кагыйдәләре, фән буларак асыл хасиятләре Ф. Әмирханның тәнкыйди гыйльми эшчәнлегендә фәнни югарылыкта эшләнә һәм хәл ителә.

**Әдәбият**

*Әмирхан Ф.* Әсәрләр: дүрт томда. 3 т. Публицистика. Казан: Татар. кит. нәшр., 1989. 512 б.

*Әмирхан Ф.* Әсәрләр: дүрт томда. 4 т. Әдәбият-сәнгать тәнкыйте, биографик материаллар. Казан: Татар. кит. нәшр., 1986. 390 б.

*Вәлиди Җ.* Әдип Фатих Әмирхан // Гыйлаҗев Т.Ш. Рецензияләрдән тәгъзияләргә: XX йөз башы татар әдәби тәнкыйте. Казан: Татар. кит. нәшр., 2008. Б. 182–186.

*Гилазов Т.Ш.* Проблема литературной репутации Г. Тукая в научно-критической мысли первой четверти XX века // Филология и культура. Philology and Culture. 2013. № 3 (33). С. 181–185.

*Gilazov T.Sh, Karabulatova I.S., SayfulinaF.S., Kurakova Ch.M. and Gulphiya Maratovna Talipova.* Between the East and the West: Phenomenon of Tartar Literary Criticism in the Lingvo-Cultural Aspect // Mediterranean Journal of Social Science. 2015. Vol 6, No 3, S 2, May 2015. P. 508–517. Doi:10.5901/mjss.2015.v6n3s2p508

http://www.mcser.org/journal/index.php/mjss/article/view/6534/6261

*Заһидуллина Д.Ф.* Әдәбият кануннары һәм заман (Татар әдәбият нәзариясенең барлыкка килүе һәм үсеш баскычлары). Казан: Татар. кит. нәшр., 2000. 271 б.

*Закирзянов А.М.* Основные направления развития современного татарского литературоведения (кон. XX – XXI в.). Казань: Ихлас, 2011. 320 с.

*Нуруллин И.З.* XX йөз башы татар әдәбияты. Урта мәктәп укытучылары, студентлар һәм югары класс укучылары өчен дәреслек-кулланма. Казан: татар. кит.нәшр., 1982. 288 б.

*Пинкевич А.* Очерки новейшей татарской литературы // Волжско-Камская речь. 1908. 21 мая.

*Сәгъди Г.* Бездә әдәби тәнкыйть / Үктәбрнең унъеллыгына. Казан: «Безнең юл». 1927. 22 б.

*Уралец К.* О татарских поэтах // Волжский листок. 1908. № 34.10 июня.

***Гыйлаҗев Таһир Шәмсегали улы,***
*филология фәннәре кандидаты,*
*Казан (Идел буе) федераль университетының*
*татар әдәбияты кафедрасы доценты*
*tgilazov@bk.ru*